ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУСАБАЙ-ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

16 декабрь 2024 ел № 20/4

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советының 2012 елның 20 ноябрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Төп тешенчәләр» 2 бүлегендә:

- егерме бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йорт – Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясы 6 елешендә билгеләнгән билгеләргә туры килә торган бина;»;

- түбәндәге эчтәлектәге кырык сигезенче – илле беренче абзацларны өстәргә:

«автомобиль юлларын төзекләндерү элементлары – юл билгеләре, юл киртәләре, светофорлар, юл хәрәкәтен җайга салу җайланмалары, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны теркәү өчен фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләре булган автоматик режимда эшләүче стационар махсус техник чаралар, рөхсәт ителгән максималь массасы 12 тоннадан артык булган транспорт чаралары тарафыннан гомуми файдаланудагы федераль әһәмияттәге автомобиль юлларына китерелә торган зыянны каплау исәбенә түләү кертүне тикшереп торучы фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләре булган автоматик режимда эшләүче стационар махсус техник чаралар, ял итү урыннары, тукталыш пунктлары, автомобиль юлларын яктырту өчен билгеләнгән объектлар, җәяүлеләр юллары, транспорт чараларының үлчәү һәм габарит контроле пунктлары, түләү алу пунктлары, транспорт чараларын кую урыннары (парковкалары), автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын саклау ечен билгеләнгән корылмалар, тротуарлар кергән корылмалар, юл хәрәкәтен, шул исәптән аның иминлеген тәэмин итү ечен билгеләнгән башка корылмалар, юл сервисы объектларыннан тыш;

юл сервисы объектлары – юл хәрәкәтендә катнашучыларга хезмәт күрсәтү ечен билгеләнгән биналар, тезелмәләр, корылмалар, башка объектлар (автозаправка станцияләре, автостанцияләр, автовокзаллар, кунакханәләр, кемпинглар, мотельләр, җәмәгать туклануы пунктлары, техник хезмәт күрсәтү станцияләре, охшаш объектлар, шулай ук аларның эшләве өчен кирәкле ял итү һәм транспорт чараларын кую урыннары);

автомобиль юл чите – автомобиль юлының конструктив элементларын, юл корылмаларын урнаштыру ечен билгеләнгән һәм юл сервисы объектлары урнашкан яки урнашырга мөмкин булган җир кишәрлекләре (җирләр категориясенә карамастан);

автомобиль юлларының юл буе полосасы – ике яктан автомобиль юл чите яны территорияләре һәм аларның чикләрендә юл хәрәкәте иминлеге таләпләрен, шулай ук автомобиль юлын реконструкцияләүнең, капиталь ремонтлауның, ремонтлауның, карап тотуның нормаль шартларын, автомобиль юлын үстерү перспективаларын исәпкә алып, аның сакланышын тәэмин итү масатында җир кишәрлекләреннән (җир кишәрлекләренең өлешләреннән) файдалануның махсус режимы билгеләнә торган территорияләр.»;

1.2. «Җирлек территорияләрен җыештыруны оештыру» 3 бүлегенең 3.7.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7.3. Калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар барлыкка килгән, эшкәртелгән, утильләштерелгән, зарарсызландырылган, башка затларга тапшырылган яисә башка затлардан алынган, шулай ук урнаштырылган калдыкларның исәбен «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында»1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә алып барырга тиеш.»;

1.3. «Аерым территорияләрдә һәм объектларда чисталык һәм тәртип тәэмин итү» 8 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 8.9 – 8.9.3 пунктларны өстәргә:

«8.9. Юл сервисы объектларын карап тоту.

8.9.1. Автомобиль юлларының юл буе полосасында яисә аларга турыдан-туры якын урында урнашкан юл сервисы объектлары өчен бүленгән территорияләрне карап тоту һәм җыештыру мондый объектларның хуҗасы (милекчесе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.9.2. Юл сервисы объектлары территорияләрен төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге үз эченә алырга тиеш:

- уңайлы хәрәкәт итү өчен каты еслек;

- территорияне яктырту, архитектура-декоратив яктырту;

- аларны урнаштыру һәм карап тоту таләпләрен үтәгән бәдрәф кабиналары;

- чүп савытлары һәм кече контейнерлар;

- яшелләндерү (газоннар, чәчәкләр) һәм яшелләндерү участокларын саклау элементлары (киртәләр).

8.9.3. Юл сервисы объектларын һәм аларга якын территорияләрне урнаштыруга һәм карап тотуга карата таләпләр үз эченә ала:

- автомобиль юлы башка автомобиль юлына тоташкан очракта, керү һәм чыгу юллары көчеш-тизлек полосалары белән җиһазландырылырга һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатында автомобиль юлын төзекләндерү элементлары белән җиһазландырылырга тиеш;

- юл сервисы объектларының көчеш-тизлек полосалары һәм территорияләре тышкы яктырту белән җиһазландырылырга тиеш;

- хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданчыгына чыгу юллары ян канаулар кергән сууткәргеч белән тәэмин ителергә тиеш, ул гамәлдә булган юлдан су бүлү системасы белән тоташа (чыгу юллары астына су үткәрү торбалары салынырга тиеш);

- хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданчыгының һәм аңа таба чыгу юлларының буй авышлыгы юлның капма-каршы ягына юнәлдерелергә тиеш. Түгәрәкләнү радиуслары чикләрендә ул 20 % булырга тиеш;

- мәйданчык һәм аңа чыгу юллары автомобиль юлы белән бертигез тотрыклы камилләштерелгән катламга ия булырга тиеш;

- «Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары. Юл билгеләрен, разметкаларны, светофорларны, юл киртәләрен һәм юнәлеш бирүче җайланмаларны куллану кагыйдәләре» ГОСТ Р 52289-2019 таләпләре нигезендә юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары булу;

- эксплуатацияләү һәм тоту процессында сервис объекты территориясендә җитешсезлекләрне бетерү «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Җәйге тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль методлары» ГОСТ Р 59292-2021 һәм «Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Кышкы тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль методлары» ГОСТ Р 59434-2021 таләпләре нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш;

- функциональ билгеләнеш буенча хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы территориясендә шул исәптән санитария-гигиена зонасы булырга тиеш;

- тышкы реклама һәм мәгълүматны урнаштыру чаралары техник яктан төзек һәм эстетик яктан каралган булырга һәм бирелгән техник шартлар нигезендә файдаланылырга тиеш;

- юл сервисы объектлары транспорт чаралары тукталышлары һәм туктап тору урыннары, шулай ук автомобиль юлыннан аларга кереп йерүне тәэмин итү максатында керү юллары, чыгу юллары һәм кушылу урыннары белән җиһазланган булырга тиеш;

- «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә юл сервисы объектларының транспорт чараларын кую урыннарында инвалидлар идарә итә торган транспорт чараларын бушлай кую ечен урыннар бүлеп бирелергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан кеннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башлыгына йекләргә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Мусабай-Завод авыл җирлеге Башлыгы З.З. Хөсәинова